СОВЕТ ПОИСЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТА-
НЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423730, село Поисево,
ул.Кирова,дом 2А,
Тел. 3-44-51

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙ-
ОНЫ ПУЧЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423730, Пучы авылы, Киров ур.,2А
нчы йорт.
Тел.3-44-51

**РЕШЕНИЕ**
19.12. 2024 года

**КАРАР**
№ 25

Актаныш муниципаль районы Пучы авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 24 маендагы 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында " 12.07.2024 ел, № 176-ФЗ Федераль законга (2024 елның 12 декабренә үзгәрешләр кертеп), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Пучы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Пучы авыл җирлеге советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Пучы авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 24 маендагы 11 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның 14 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларына карата салым ташламасы бирелми, мондый салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннарынан тыш, һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2_1 бүлегендә урнашкан урыннар моңа керми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштырырга.

Актаныш муниципаль районы
Пучы авыл Җирлеге Совет рәисе — Ф.Ф. Файзуллин